**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17йорт,Актаныш ав.,423740

Тел.(85552)3-44-22,факс (85552) 3-44-14,E-mail:aktanysh@tatar.ru,www.aktanysh.tatarstan.ru

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

30. 1 1. 2018 | ________

2019 елга Актаныш муниципаль районы балаларга өстәмә белем бирүче туристик-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлешле мәгариф оешмаларының һәм балаларга өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында

«Мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балаларга өстәмә белем бирү туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, өстәмә белем бирү учреждениеләрен финанслау нормативларын исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында" 2009 елның 31 декабрендәге 939 номерлы карары, Татарстан Республикасы һәм муниципаль берәмлек Уставы нигезендә, «Актаныш муниципаль районы» Татарстан Республикасы Башкарма комитеты, **КАРАР БИРӘ:**

1.2019 елга расларга:

Актаныш муниципаль районы балаларына өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында туристик-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлештәге һәм өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга кушымта итеп бирелә торган норматив чыгымнар; туристлык-туган якны өйрәнү, экологобиологик, хәрби-патриотик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлешле һәм күппрофильле мәгариф оешмаларында балаларга өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнарга карата 0,5 күләмендә өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив коэффициент.

2. Актаныш муниципаль районының финанс-бюджет палатасында түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларын финанслау; әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары гамәлдә булган чоры дәвамында балаларга өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт

законнарында һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә башкарыла торган хезмәт хакын индексацияләү белән бер үк вакытта яңадан карау.

3. Әлеге карар аның Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль мәсьәләләр буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Л.Ф.Нурлыевага йөкләргә

Башкарма комитет җитәкчесе И.Ш. Бариев